ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

07.11.2024 ел          Баулы шәһәре          № 157

Баулы муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укыган укучылар өчен түләүсез кайнар туклануны оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарын һәм 2025 ел һәм 2026, 2027 еллар план чорына Баулы муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укыган укучылар өчен кайнар туклануның уртача бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 14 июлендәге 588 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында һәм муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы, күрсәтелгән мәгариф учреждениеләрендә шундый укучылар санының 100 процентын колачлауны тәэмин итүче укучыларның Татарстан Республикасында түләүсез кайнар туклануны оештыру чаралары исемлеген раслау турында» карары белән, «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» СанПин 2.4.5.2409-08 таләпләрен үтәү максатларында сәламәт туклануны оештыру өлешендә, шулай ук укучыларның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру өчен, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымталарны расларга:

2025 ел һәм 2026, 2027 еллар план чорына Баулы муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары

буенча укыган укучылар өчен түләүсез кайнар туклануны оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнар (1-нче номерлы кушымта);

2025 ел һәм 2026, 2027 еллар план чорына Баулы муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укыган укучылар өчен кайнар туклануның уртача бәясе (2-нче номерлы кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 7 ноябрендәге
157 номерлы карары белән
РАСЛАНГАННАР
1-нче номерлы кушымта

2025 ел һәм 2026, 2027 еллар план чорына Баулы муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укыган укучылар өчен түләүсез кайнар туклануны оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнары

| Норматив чыгымнар атамасы | Көненә бер укучыга тәгаенләнгән норматив чыгымнар күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|
| | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Баулы муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укыган укучылар өчен түләүсез кайнар туклануны оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнары | 69,43 | 72,21 | 75,1 |

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 7 ноябрендәге
157 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН
2-нче номерлы кушымта

2025 ел һәм 2026, 2027 еллар план чорына Баулы муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укыган укучылар өчен кайнар туклануның уртача бәясе

| Күрсәткеч атамасы | Көненә бер укучыга тәгаенләнгән күрсәткеч билгесе, сумнарда | | |
|---|---|---|---|
| | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укыган укучылар өчен кайнар туклануның уртача бәясе | 69,43 | 72,21 | 75,1 |